**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**Алькеевского**
**муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әлки**
**муниципаль районы**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Базарлы Матак авылы **КАРАР**

2022 елның 28 октябре 391№

Мәгариф, мәдәният һәм спорт муниципаль оешмаларында өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) ярдәм чаралары күрсәтү турында

Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 21 сентябрендәге«Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 647 номерлы Әмере, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2012 елның 29 декабрендәге «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 273 номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 20 октябрендәге «Россия Федерациясе Хәрби Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнарына ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 1122 номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТТЕ:

1. Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) түбәндәге өстәмә ярдәм чараларын билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) алына торган түләүдән азат итү;

-Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмасына чираттан тыш кабул итүгә хокук бирү;

-районның түбәндәге муниципаль учреждениеләренә бушлай керү хокукын бирү:

- «С.М. Лисенков исемендәге Тарихи-туган якны өйрәнү музее» МБУК
- «Әлки киноучреждениесе» МБУ

- Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Спорт мәктәбе» МБУ
- “Әлки балалар музыка мәктәбе” ӨББ МБО
- «Балалар иҗат йорты» ӨББ МБО
- «Алинә» универсаль спорт залы» УСЗ МБУ
- «Ләйсән» ябык йөзү бассейны МБУ
- «Имәнлек» БСЛ МБУ

2. «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ һәм «Әлки район мәдәният бүлеге» МКУ, яшьләр сәясәте һәм спорт бүлегенә югары санап үтелгән ведомство буйсынуындагы учреждениеләрдә оештырырга:

1.2. өлешчә мобилизацияләү кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) армиягә чакыру турындагы хәрби комиссариат документы нигезендә ярдәм итү чараларын күрсәтү;

2.2. өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар кайтканда күрсәтелгән ярдәм чараларының гамәлдә булуын контрольдә тоту максатыннан хәрби комиссариат белән үзара хезмәттәшлекне урнаштыру.

4. Әлеге карарның 1 пунктында каралган өстәмә социаль ярдәм чараларын сорап мөрәҗәгать итү Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 21 сентябрендәге "Россия Федерациясендә өлешчә мобилизацияне игълан итү турында» 647 номерлы Әмере нигезендә хәрби хезмәткә чакырылган гражданның мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылганнарны җыю урыннарына һәм (яки) кабул итү пунктларына (урыннарына) барып урнашкан көннән хәл ителә.

5. Әлеге карарның 1 пунктында каралган ярдәм чараларын күрсәтү Россия Федерациясе гражданнары Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә мобилизация буенча хәрби хезмәт узган чорда гамәлгә ашырыла.

6. Татарстан Республикасы Әлки һәм Спас районнары хәрби комиссариатына граждан өлешчә мобилизацияләү кысаларында хәрби хезмәтен туктаткан очракта 10 календарь көн эчендә Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә гражданның ярдәм чаралары алу өчен нигез юкка чыгуы турында мәгълүмат бирергә тәкъдим итәргә .

7. «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУ Әлки муниципаль районының мәгариф оешмаларында өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның гаиләләреннән тәрбияләнүчеләрне тотуны финанслауны тәэмин итәргә.

8. Әлеге карарның гамәлдә булуы гражданның өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәт узу вакытына 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

9.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль мәсьәләләр буенча Башкарма комитет җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Әлкимуниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе: Р.Х.Морадымов